**ЗАКОН**
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

# О гражданской обороне в Республике Татарстан

Принят
Государственным Советом
Республики Татарстан
20 февраля 2020 года

Статья 1. **Предмет регулирования настоящего Закона**

Настоящий Закон в соответствии Федеральным законом от 12 февраля 1998 года № 28-ФЗ «О гражданской обороне» (далее – Федеральный закон) регулирует отдельные вопросы в области гражданской обороны в Республике Татарстан.

Статья 2. **Основные понятия, используемые в настоящем Законе**

Основные понятия, используемые в настоящем Законе, применяются в том же значении, что и в Федеральном законе.

Статья 3. **Правовое регулирование в области гражданской обороны**

1. Правовое регулирование в области гражданской обороны осуществляется в соответствии с Федеральным законом, другими федеральными законами и иными нормативными правовыми актами Российской Федерации, настоящим Законом и иными нормативными правовыми актами Республики Татарстан.
2. Органы местного самоуправления в Республике Татарстан в пределах своих полномочий могут принимать муниципальные правовые акты, регулирующие вопросы гражданской обороны.

Статья 4. **Задачи в области гражданской обороны**

Основными задачами в области гражданской обороны являются:
1) подготовка населения в области гражданской обороны;

2) оповещение населения об опасностях, возникающих при военных конфликтах или вследствие этих конфликтов, а также при чрезвычайных ситуациях природного и техногенного характера;

3) эвакуация населения, материальных и культурных ценностей в безопасные районы;

4) предоставление населению средств индивидуальной и коллективной защиты;

5) проведение мероприятий по световой маскировке и другим видам маскировки;

6) проведение аварийно-спасательных и других неотложных работ в случае возникновения опасностей для населения при военных конфликтах или вследствие этих конфликтов, а также при чрезвычайных ситуациях природного и техногенного характера;

7) первоочередное жизнеобеспечение населения, пострадавшего при военных конфликтах или вследствие этих конфликтов, а также при чрезвычайных ситуациях природного и техногенного характера;

8) борьба с пожарами, возникшими при военных конфликтах или вследствие этих конфликтов;

9) обнаружение и обозначение районов, подвергшихся радиоактивному, химическому, биологическому или иному заражению;

10) санитарная обработка населения, обеззараживание зданий и сооружений, специальная обработка техники и территорий;

11) восстановление и поддержание порядка в районах, пострадавших при военных конфликтах или вследствие этих конфликтов, а также при чрезвычайных ситуациях природного и техногенного характера;

12) срочное восстановление функционирования необходимых коммунальных служб в военное время;

13) срочное захоронение трупов в военное время;

14) обеспечение устойчивости функционирования организаций, необходимых для выживания населения при военных конфликтах или вследствие этих конфликтов, а также при чрезвычайных ситуациях природного и техногенного характера;

15) обеспечение постоянной готовности сил и средств гражданской обороны.

Статья 5. **Полномочия Государственного Совета Республики Татарстан в области гражданской обороны**

Государственный Совет Республики Татарстан принимает законы Республики Татарстан в области гражданской обороны, контролирует их исполнение, осуществляет иные полномочия в соответствии с законодательством Российской Федерации и законодательством Республики Татарстан.

Статья 6. **Полномочия Президента Республики Татарстан в области гражданской обороны**

Президент Республики Татарстан в пределах своей компетенции:

1) осуществляет руководство гражданской обороной на территории Республики Татарстан;

2) обеспечивает согласованное функционирование и взаимодействие органов государственной власти при решении задач и (или) выполнении мероприятий по гражданской обороне на территории Республики Татарстан;

3) осуществляет иные полномочия в сфере руководства гражданской обороной в соответствии с законодательством Российской Федерации.

Статья 7. **Полномочия Кабинета Министров Республики Татарстан в области гражданской обороны**

1. Кабинет Министров Республики Татарстан в пределах своей компетенции:

1) организует проведение мероприятий по гражданской обороне, разрабатывает и реализовывает планы гражданской обороны и защиты населения;

2) создает и поддерживает в состоянии готовности силы и средства гражданской обороны;

3) организует подготовку населения в области гражданской обороны;

4) создает и поддерживает в состоянии постоянной готовности к использованию технические системы управления гражданской обороны, системы оповещения населения об опасностях, возникающих при военных конфликтах или вследствие этих конфликтов, а также при чрезвычайных ситуациях природного и техногенного характера, защитные сооружения и другие объекты гражданской обороны;

5) планирует мероприятия по подготовке к эвакуации населения, материальных и культурных ценностей в безопасные районы, их размещению, развертыванию лечебных и других учреждений, необходимых для первоочередного обеспечения пострадавшего населения;

6) планирует мероприятия по поддержанию устойчивого функционирования организаций в военное время;

7) создает и содержит в целях гражданской обороны запасы материально-технических, продовольственных, медицинских и иных средств;

8) обеспечивает своевременное оповещение населения, в том числе экстренное оповещение населения, об опасностях, возникающих при военных конфликтах или вследствие этих конфликтов, а также при чрезвычайных ситуациях природного и техногенного характера;

9) определяет перечень организаций, обеспечивающих выполнение мероприятий республиканского уровня по гражданской обороне.

2. Полномочия, указанные в части 1 настоящей статьи, осуществляются непосредственно Кабинетом Министров Республики Татарстан или уполномоченными им органами исполнительной власти Республики Татарстан.

Статья 8. **Полномочия органов местного самоуправления и организаций в области гражданской обороны**

Полномочия органов местного самоуправления и организаций в области гражданской обороны определяются в соответствии с законодательством Российской Федерации.

Статья 9. **Руководство гражданской обороной**

1. Руководство гражданской обороной на территории Республики Татарстан осуществляет Президент Республики Татарстан.
2. Заместителем руководителя гражданской обороны Республики Татарстан является Премьер-министр Республики Татарстан.
3. Руководство гражданской обороной на территории муниципальных образований Республики Татарстан осуществляют руководители исполнительных комитетов муниципальных образований.
4. Руководители гражданской обороны всех уровней несут персональную ответственность за организацию и проведение мероприятий по гражданской обороне и защите населения.

Статья 10. **Органы, осуществляющие управление гражданской обороной**

Органами, осуществляющими управление гражданской обороной, являются:

1) федеральный орган исполнительной власти, уполномоченный на решение задач в области гражданской обороны;

2) территориальные органы – органы, уполномоченные решать задачи гражданской обороны и задачи по предупреждению и ликвидации чрезвычайных ситуаций по субъектам Российской Федерации;

3) структурные подразделения федеральных органов исполнительной власти и органов местного самоуправления, уполномоченные на решение задач в области гражданской обороны;

4) структурные подразделения (работники) организаций, уполномоченные на решение задач в области гражданской обороны, создаваемые (назначаемые) в порядке, установленном Правительством Российской Федерации.

Статья 11. **Координация деятельности органов управления гражданской обороной и сил гражданской обороны**

Обеспечение координации деятельности органов управления гражданской обороной, управления силами и средствами гражданской обороны, организации информационного взаимодействия федеральных органов исполнительной власти, органов исполнительной власти Республики Татарстан, органов местного самоуправления в Республике Татарстан и организаций при решении задач в области гражданской обороны, а также при осуществлении мер информационной

поддержки принятия решений в области гражданской обороны на республиканском уровне осуществляет центр управления в кризисных ситуациях территориального органа, подведомственного федеральному органу исполнительной власти, уполномоченному на решение задач в области гражданской обороны, в порядке, установленном федеральным органом исполнительной власти, уполномоченным на решение задач в области гражданской обороны.

Статья 12. **Финансирование мероприятий по гражданской обороне и защите населения**

1. Обеспечение мероприятий республиканского уровня по гражданской обороне, защите населения и территории Республики Татарстан является расходным обязательством Республики Татарстан.

2. Обеспечение мероприятий местного уровня по гражданской обороне, защите населения и территории муниципального образования Республики Татарстан является расходным обязательством муниципального образования Республики Татарстан.

3. Обеспечение мероприятий по гражданской обороне, проводимых организациями, осуществляется за счет средств организаций.

Статья 13. **Вступление в силу настоящего Закона**

Настоящий Закон вступает в силу через 10 дней после дня его официального опубликования.

Президент
Республики Татарстан Р.Н. Минниханов

АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН * ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ГОМУМИ БУЛЕК

Казань, Кремль
13 марта 2020 года
№ 10-ЗРТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# Татарстан Республикасында гражданнар оборонасы турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2020 елның 20 февралендә
кабул ителде

## 1 статья. Әлеге Законның җайга салу предметы

Әлеге Закон «Гражданнар оборонасы турында» 1998 елның 12 февралендәге 28-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – Федераль закон) нигезендә Татарстан Республикасында гражданнар оборонасы өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга сала.

## 2 статья. Әлеге Законда кулланыла торган төп төшенчәләр

Әлеге Закондагы төп төшенчәләр Федераль законда кулланылган мәгънәләрендә кулланыла.

## 3 статья. Гражданнар оборонасы өлкәсендә хокукый җайга салу

1. Гражданнар оборонасы өлкәсендә хокукый җайга салу Федераль закон, башка федераль законнар һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары, әлеге Закон һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә гамәлгә ашырыла.

2. Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнары үз вәкаләтләре чикләрендә гражданнар оборонасы мәсьәләләрен җайга сала торган муниципаль хокукый актлар кабул итә ала.

## 4 статья. Гражданнар оборонасы өлкәсендәге бурычлар

Гражданнар оборонасы өлкәсендәге төп бурычлар булып түбәндәгеләр санала:

1) гражданнар оборонасы өлкәсендә халыкны әзерләү;

2) хәрби конфликтлар вакытында яисә әлеге конфликтлар аркасында, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдә килеп чыга торган хәвефләр турында халыкка хәбәр итү;

3) халыкны, матди һәм мәдәни кыйммәтләрне имин районнарга эвакуацияләү;

4) халыкка индивидуаль һәм коллектив саклану чаралары тарату;

5) яктылык маскировкасы һәм маскировканың башка төрләре буенча чаралар уздыру;

6) хәрби конфликтлар вакытында яисә әлеге конфликтлар аркасында, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдә халык өчен куркыныч туган очракта һәлакәттән коткару эшләрен һәм башка кичектергесез эшләрне башкару;

7) хәрби конфликтлар вакытында яисә әлеге конфликтлар аркасында, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдә зыян күргән халыкның яшәешен беренче чиратта тәэмин итү;

8) хәрби конфликтлар вакытында яисә әлеге конфликтлар аркасында килеп чыккан янгыннарга каршы көрәшү;

9) радиоактив, химик, биологик яки башка төр зарарлануга дучар булган районнарны ачыклау һәм билгеләү;

10) халыкны санитария ягыннан чистарту, биналарны һәм корылмаларны зарарсызландыру, техниканы һәм территорияләрне махсус эшкәртү;

11) хәрби конфликтлар вакытында яисә әлеге конфликтлар аркасында, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдә зыян күргән районнарда тәртипне торгызу һәм саклау;

12) сугыш вакытында тиз арада кирәкле коммуналь хезмәтләрнең эшчәнлеген торгызу;

13) сугыш вакытында мәетләрне кичекмәстән җирләү;

14) хәрби конфликтлар вакытында яисә әлеге конфликтлар аркасында, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдә халыкның яшәве өчен кирәкле оешмаларның тотрыклы эшчәнлеген тәэмин итү;

15) гражданнар оборонасы көчләренең һәм чараларының даими әзерлектә булуларын тәэмин итү.

5 статья. **Гражданнар оборонасы өлкәсендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы вәкаләтләре**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы гражданнар оборонасы өлкәсендә Татарстан Республикасы законнарын кабул итә, аларның үтәлешен контрольдә тота, Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.

6 статья. **Гражданнар оборонасы өлкәсендә Татарстан Республикасы Президенты вәкаләтләре**

Татарстан Республикасы Президенты үз компетенциясе чикләрендә түбәндәгеләрне башкара:

1) Татарстан Республикасы территориясендә гражданнар оборонасына җитәкчелек итә;

2) Татарстан Республикасы территориясендә гражданнар оборонасы буенча

мәсьәләләрне хәл иткәндә һәм (яисә) чараларны үтәгәндә дәүләт хакимияте органнарының килешеп эшләвен һәм үзара хезмәттәшлеген тәэмин итә;

3) гражданнар оборонасына җитәкчелек итү өлкәсендә Россия Федерациясе законнары нигезендә башка вәкаләтләрне башкара.

7 статья. **Гражданнар оборонасы өлкәсендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты вәкаләтләре**

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты үз компетенциясе чикләрендә түбәндәгеләрне башкара:

1) гражданнар оборонасы буенча чаралар уздыруны оештыра, гражданнар оборонасы һәм халыкны яклау планнарын эшли һәм гамәлгә ашыра;

2) гражданнар оборонасы көчләрен һәм чараларын булдыра һәм аларны даими әзерлектә тота;

3) гражданнар оборонасы өлкәсендә халыкны әзерләүне оештыра;

4) гражданнар оборонасы белән идарә итүнең техник системаларын, хәрби конфликтлар вакытында яисә әлеге конфликтлар аркасында, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдә килеп чыга торган хәвефләр турында халыкка хәбәр итү системасын, саклагыч корылмаларны һәм гражданнар оборонасының башка объектларын булдыра һәм аларны файдалануга даими әзерлек хәлендә тота;

5) халыкны, матди һәм мәдәни кыйммәтләрне имин районнарга эвакуацияләүне әзерләү, аларны урнаштыру, зыян күргән халыкны беренче чиратта тәэмин итү өчен кирәкле дәвалау учреждениеләрен һәм башка учреждениеләрне эшләтеп җибәрү чараларын планлаштыра;

6) сугыш вакытында оешмаларның тотрыклы эшчәнлегенә ярдәм итү чараларын планлаштыра;

7) гражданнар оборонасы максатларында матди-техник чаралар, азык-төлек, медицина чаралары һәм башка чаралар запасын булдыра һәм карап тота;

8) хәрби конфликтлар вакытында яисә әлеге конфликтлар аркасында, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдә килеп чыга торган хәвефләр турында халыкка үз вакытында, шул исәптән ашыгыч рәвештә, хәбәр итүне тәэмин итә;

9) гражданнар оборонасы буенча республика дәрәҗәсендәге чараларның үтәлешен тәэмин итә торган оешмалар исемлеген билгели.

2. Әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән вәкаләтләр турыдан-туры Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты яисә ул вәкаләт биргән Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары тарафыннан гамәлгә ашырыла.

8 статья. **Гражданнар оборонасы өлкәсендә җирле үзидарә органнары һәм оешмалар вәкаләтләре**

Җирле үзидарә органнарының һәм оешмаларның гражданнар оборонасы өлкәсендәге вәкаләтләре Россия Федерациясе законнары нигезендә билгеләнә.

9 статья. **Гражданнар оборонасына җитәкчелек итү**

1. Татарстан Республикасы территориясендә гражданнар оборонасына Татарстан Республикасы Президенты җитәкчелек итә.

2. Татарстан Республикасы Премьер-министры Татарстан Республикасы гражданнар оборонасы җитәкчесе урынбасары булып тора.

3. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре территориясендә гражданнар оборонасына җитәкчелек итүне муниципаль берәмлекләрнең башкарма комитетлары җитәкчеләре гамәлгә ашыра.

4. Гражданнар оборонасының барлык дәрәҗәләрдәге җитәкчеләре гражданнар оборонасы һәм халыкны яклау буенча чараларны оештыру һәм уздыру өчен шәхсән җаваплылыкка ия була.

10 статья. **Гражданнар оборонасы белән идарә итүне гамәлгә ашыра торган органнар**

Гражданнар оборонасы белән идарә итүне гамәлгә ашыручы органнар булып түбәндәгеләр санала:

1) гражданнар оборонасы өлкәсендә мәсьәләләрне хәл итүгә вәкаләтле федераль башкарма хакимият органы;

2) территориаль органнар – Россия Федерациясе субъектлары буенча гражданнар оборонасы мәсьәләләрен һәм гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү мәсьәләләрен хәл итүгә вәкаләтле органнар;

3) федераль башкарма хакимият органнарының һәм җирле үзидарә органнарының гражданнар оборонасы өлкәсендә мәсьәләләрне хәл итүгә вәкаләтле структур бүлекчәләре;

4) оешмаларның гражданнар оборонасы өлкәсендә мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтенә ия булган, Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртиптә булдырыла (билгеләп куела) торган структур бүлекчәләре (хезмәткәрләре).

11 статья. **Гражданнар оборонасы белән идарә итү органнары эшчәнлеген һәм гражданнар оборонасы көчләрен координацияләү**

Гражданнар оборонасы белән идарә итү органнары эшчәнлеген, гражданнар оборонасы көчләре һәм чаралары белән идарә итүне координацияләү, гражданнар оборонасы өлкәсендә мәсьәләләрне хәл итү буенча, шулай ук республика дәрәҗәсендә гражданнар оборонасы өлкәсендә карарлар кабул итүгә мәгълүмати ярдәм чараларын гамәлгә ашырганда федераль башкарма хакимият оранnарының, Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының, Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнарының һәм оешмаларның мәгълүмати хезмәттәшлеген оештыру гражданнар оборонасы өлкәсендә мәсьәләләрне хәл итүгә вәкаләтле федераль башкарма хакимият органы билгеләгән тәртиптә гражданнар оборонасы өлкәсендә мәсьәләләрне хәл итүгә вәкаләтле федераль башкарма

хакимият органына ведомство буйсынуындагы территориаль органның кризислы шартларда идарә итү үзәге тарафыннан тәэмин ителә.

12 статья. **Гражданнар оборонасы һәм халыкны яклау буенча чараларны финанслау**

1. Гражданнар оборонасы, Татарстан Республикасы халкын һәм территориясен яклау буенча республика дәрәҗәсендәге чараларны тәэмин итү Татарстан Республикасының чыгым йөкләмәсе булып тора.

2. Гражданнар оборонасы, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге халкын һәм территориясен яклау буенча җирле дәрәҗәдәге чараларны тәэмин итү Татарстан Республикасы муниципаль берәмлегенең чыгым йөкләмәсе булып тора.

3. Оешмалар тарафыннан гражданнар оборонасы буенча уздырыла торган чараларны тәэмин итү оешмалар акчасы исәбеннән гамәлгә ашырыла.

13 статья. **Әлеге Законның үз көченә керүе**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2020 ел, 13 март
№ 10-ТРЗ